**ГЛАВА БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422646, Олы Әшнәк,
Г.Тукай урамы, 28а йорт

Тел.: (84361) 27-732, факс: (84361) 27-738, эл.адрес: Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

09 октябрь 2024 ел Олы Әшнәк авылы № 4

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Кече Әшнәк торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Олы Әшнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2024 елның 23 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) һәм м махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү системаларын, су кудыру башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистарту һәм Кече Әшнәк авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;

- Олы Әшняк һәм Кече Әшняк авылларының су скважинасын яңарту;

- авыл чикләрендә (Кече Әшнәк авылында) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;

- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;

- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш китертү өчен транспорт хезмәтләре өчен түләү;

Торак пункт территориясен төзекләндерү:

- Кече Әшнәк авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);

- чүп үләннәрен  чабу өчен чапкыч сатып алу;

- урамнарны яктыртуны җайга салу;

- Олы Әшняк һәм Кече Әшняк авылларының су скважиналарын яңарту;

- Кече Әшнәк авылы урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең  түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе  районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Красноармейская урамы, 32а һәм Татарстан Республикасы Балык  Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда кабул ителү белән 3 көн эчендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге
Башлыгы Р.А.Хөснетдинова